ФИРЯ | ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Этнокультурная составляющая новых УМК по родной (татарской) литературе

Мухарлямова Гульназ Нурфатовна,
заведующая отделом национального образования Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан,
кандидат филологических наук

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ



ӘЙДӘГЕЗ МӘКТӘПКӘ!

Исәнмесез, минем кадерле дусларым! Мена сагынып көткән очрашыр вакыт та килеп җитте. Күрәм: сез тагын да зур үсеп, акыллырак, тәрбиялерәк һәм матуррак булып килгәнсез. Сез дә мәктәпне, укытучыларыгызны, дусларыгызны, китапларыгызны сагынгансыздыр. Сезнең хәтерегездә җәйнең искиткеч матур мизгелләре сакланып калгандыр. Сез аларны дусларыгыз белән бик телән уртаклашырсыз дип уйлыйбыз. Без сезгә кабат кызыклы һәм мавыктыргыч китап битләрен ачабыз. Рәхим итегез, уңышлар сезгә!

Исәнмесез, дуслар! Мена без тагын бергә. Сезнең белән кабат очрашуыбызга бик шат.

Минем җәй бик матур булды. Бакчада дәү әтиемә булыштым. Гөмбә, җиләк җыйдык. Алмаларны киптереп тә куйдык. Китаплар укыдым. Дусларым белән уйнадым. Мәктәп хәлләрен сөйләшеп торырга сүз куештык.

Мин кызыклы китаплар укыдым. Табигатьтә ял иттем. Иң күңеллесе дәү әниләр белән ял итү булды.

Минем җәй дә бик күңелле үзды. Дәү әнием төрле шифалы үләннәрне танырга өйрәтте. Яңа дуслар таптым. Таныш булыгыз, мена минем дустым Сара. Быел ул безнең белән бергә укыячак. Бик тырыш һәм тәрбияле кыз.

Шигърият һәрвакыт матурлыкка омтыла. Тормыштагы ямьсезлекне тасвирлаганда да, ул, матурлыкны эзләүнең бер ысулы буларак, алга чыга, аны кешелекнең бу дөньяда тереклек итүнең иң мөһим чыганагы итеп саный. Матурлык — һәр мизгелдә, ул тирә-якның, тереклекнең, табигатьнең гүзәллегендә, камиллегендә генә түгел, рухи байлыкның асылында, безнең — кешеләрнең матур гамәлләрендә, изгелегендә дә чагылыш таба. Аны күрә, аңлый, бәяли, саклый белергә кирәк.

Мөдәррис Әгъләмов

МАТУРЛЫК МИНЕМ БЕЛӘН

Зур, матур, биек йортлар,
Тәрәзәләрдә — утлар...
Ишектән килеп керәм.
Кайда гына барсам да,
Матурлык минем белән.

Сикереп төшәм суларга,
Шундый рәхәт суларга!
Тауларга күтәреләм.
Кайда гына булсам да,
Матурлык минем белән.

Алда — күл, янда — болын...
Уйнаклап йөри колын...
Мин дә тәгәрим, көләм,
Чөнки, кайда булсам да,
Матурлык минем белән.

Җирем иркен, илем киң,
Горур йөрергә мөмкин,
Имичә башны түбән...
Чөнки кайда булсам да,
Матурлык минем белән.

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә, бераздан өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл өйләренең ишекләрен ачу балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә авыр булганлыктан, ябышып катканча көтеп торам икән.

Карчык исә үзенең «Кадалмас әле килмешәк!» дигән «шәфкатьле» фикере белән мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән.

Мин бу карчыкта торган вакытта анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк: ул бервакыт мине үзе янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән минутларда миндә, бала булсам да, мин хәзер дә, атта утырып, Саснага барганымны, үземне бер киң һәм рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганны онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады — анысын белмим, ләкин үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Хаҗиморат Казаков. Кечкенә Тукай (фрагмент)

Чынбарлыктан ерак торсалар да, әкиятләрдә халыкның хыял, теләкләре гәүдәләнеш ала. Халкыбызга хас булган тормышны матур итеп күрергә теләү, гаделлек сөю, тырыш һәм батыр йөрәклеләргә өстенлек бирү, әдәплеләрне ярату әкиятләрнең эчтәлегендә урын ала.

Төрле халыкларда эчтәлеге белән бер-берсенә якын торган әкиятләрне очратырга була. Бу һәр халыкның яхшы гамәлләрне өстен күрүе, гаделлек, тәрбиялелекне зурлавыннан килә.

Әкиятләрдә сөйләүче образы әһәмияткә ия. Ул һәрнәрсәне җанландырып, мавыктыргыч итүгә ярдәм итә. Әкиятнең теленең матурлыгы, образлылыгы, хисләрнең гел алышынып торуы укучыга тәэсирлелекне арттыра.

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

ХӘЙЛӘКӘР ТӨЛКЕ

Татар халык әкияте

Көннәрдән бер көнне бер Төлке юл буйлап бар икән, бер сарык аягы тапкан. Барып, бер авылга кереп, бер адәмнән йокларга фатир сораган. Бу кеше әйткән:

— Безнең өебез бик кечкенә, син сыярлык урын юк,— дигән.

Төлке әйткән:

— Мин үзем кечкенә генә сәкедә ятармын, койрыгымны сәке астына куярмын,— дигән.

Фатир иясе:

— Алай булса ярар,— дигән.

Төлке әйткән хуҗага:

— Бу сарык аягын җыеп куйсагыз ла,— дигән.

Хуҗа җыеп куйган. Төлке хуҗаның кая куйганын карап торган. Хуҗалар йоклагач, Төлке төнлә, торып, аякны икенче җиргә алып куйган. Иртән торганнар. Төлке хуҗадан аякны сораган. Хуҗа куйган җиреннән алып бирмәкче булса, урынында аяк юк икән. Төлке әйткән:

Аяк булмаса, урынына бер тавык рәхим итегез,— дигән.

Хуҗа Төлкегә бер тавык биргән. Төлке тавыкны алып чыгып киткән.

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ
РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Габдулла Тукайның әкият-поэмасының бик тәэсирле һәм матур булуы башка иҗат вәкилләренә дә илһам чыганагы була. Татар опера сәнгатенең йөзек кашы булган «Шүрәле» балеты (композитор Фәрит Яруллин музыкасы) иҗат ителә. Сынлы сәгать һәм рәсем сәнгатендә Шүрәле образына еш мөрәҗәгать итәләр. Халкыбызның танылган сынчы һәм рәссаме Бакый Урманче иҗатында ул аеруча зур урын алып тора.

Татар халкының күренекле шәхесләре

Тукай тормышы һәм иҗатын рәсем һәм сынлы сәнгатьтә иң тулы чагылдыручы — Бакый Урманче.

***Бакый Урманче** — нәкышьче, сынчы, график, педагог, ТАССРның һәм РСФСРның халык рәссамы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Бакый Урманченың графика мирасы гына да өч меңнән артык хезмәтен үз эченә ала. ГабдуллаТукайның «Шүрәле» поэмасына ул йөздән артык график хезмәт багышлый, шагыйрьнең «Кисекбаш» поэмасына, Дәрдемәнд шигырьләренә «Сак-Сок» бәетенә иллюстрация сериясе иҗат итә.*

Татар халкының күренекле шәхесләре

***Фәрит Яруллин** — күренекле татар композиторы. Фәрит Яруллин камера-инструменталь әсәрләр, романслар, җырлар яза. Халык җырларын да эшкәртеп татар музыкасы үсешенә зур өлеш кертә. Ул — беренче татар балеты «Шүрәле»нең авторы.*

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

«Шүрәле» — сәхнә тарихында беренче татар балеты була. Балет Габдулла Тукай әкиятләре нигезендә композиторлар Фәрит Яруллин, Әхмәт Фәйзи, балетмейстер Л.В. Якобсон тарафыннан иҗат ителә. Өч күренештән дүрт картинадан торган «Шүрәле» балеты 1939 елда бик кыска вакыт эчендә язылып бетә. Ләкин Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле аны сәхнәгә кую озак елларга кичектерелә. Фәрит Яруллин үзе сугышка китә. Кызганыч, 1944 елда сугыш кырында һәлак була. «Шүрәле» балетын үзе күрми кала. Бу хакта ул бер хатында болай дип яза: «Минем «Шүрәле»не шулкадәр сәхнәдә күрәсем килде. Бер генә күзем белән булса да... Аның музыкасы миндә яши, ул һәрвакыт минем белән бергә». Ләкин аның бу теләге чынга ашмый кала. Ниһаять, балет сугыш бетәр алдыннан 1945 елның 12 мартында Татар опера һәм балет театрында куела. Бүген дә ул сәхнәдән төшми. Санкт-Петербургтагы Мариин театры һәм Казандагы Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры сәхнәләрендә куела.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Татар авылларында элек-электән аулак өйгә бару традициясе яшәгән. Караңгы төшү белән хатын-кызлар бер йортта җыелып кич утырганнар. Бу вакытта алар кул эше белән шөгыльләнгәннәр: кызлар җеп эрләгәннәр, үзләренә бирнәлеккә сөлге, ашъяулык, пәрдәләр, сөйгәннәренә кулъяулык чиккәннәр, олырак хатыннар шәл, оекбаш, бияләйләр бәйләгәннәр. Шул вакытта күңелдә ача белгәннәр: табышмак әйтешкәннәр, уен оештырганнар, җырлап, биеп алганнар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Җырны кемнәр җырлый? Алар нәрсә өчен борчыла?
2. Җырда кайсы чорда яшәүче кызлар турында сүз бара? Ничек белдең?

Мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

булса авыр, зур эшне, ярдәм итү нияте белән, ирекле рәвештә, бергә җыелып башкару йоласы. Татар халкында тула басу, җеп эрләү, киндер агарту, каз өмәсе кебек өмәләр булган. Ялгыз яки гаилә көче белән генә башкарып булмаган эшләргә өмә оештырганнар. Ул исә эшне тиз арада бетерергә ярдәм иткән. Өмә эше үрчемле, дигән мәкаль-әйтем шул турыда.

Халкыбызның гасырлар буена тупланып, буыннан-буынга күчеп сакланган күнел

Фольклор инглиз теленнән «халык акылы» дип тәрҗемә ителә. Халык иҗатында шул халыкның тормыш рәвеше, хезмәт төрләре дә, рухи күңел байлыгы, әхлагы, уй-хыяллары, гаделлек өчен көрәше, киләчәккә омтылыш-теләкләре дә чагылыш таба.

Халыкның фольклоры аша ерак заманнарда яшәгән бабаларыбызның тормышын, күңел дөньясын аңлый алабыз.

Татар фольклоры халкыбыз көнкүреше белән бик нык кереш еп үскән. Күмәк хезмәт — өмәләр — җыр, тапкыр сүз, уеннар белән кушылып китә торган булган. Кыз озату, килен төшерү, бәби туе, орлык чәчүнең үз йоласы булган кебек, йорт күтәрү, киндер тукмаклау, тула басу, каз өмәләре — һәркайсы уен-җырлы, такмазалы итеп, яшьләр бәйрәме итеп үткәрелгән. Анда режиссер да, башкаручы да, тамашачы да — халык үзе.

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ
РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ





ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ
РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Күмәченне ашатмасаң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан. Ары каранган, бире каранган да басу кырыенда үсеп утырган куш каенга менеп киткән, ди. Соры бүре куш каенның тамырларын казый башлаган, ди.

Гөлчәчәк бик курка икән, ди.

— Инде монда кайтып җиткәч тә, әниләрне күрмичә үләрмен микәнни соң? — дип әйтеп, бик елап утыра икән, шунда куш каен башына бер сыерчык килеп кунган, ди. Гөлчәчәк сыерчыкка ялына башлаган:

Ала муен сыерчык,
Кола муен сыерчык,
Чәч бөртегем – әманәтем,
Илтеп бирче, сыерчык,
Илтеп бирче, сыерчык.

5. Әсәрнең бу өлешендә чынлыкта була алмый торган тагын нинди хәлләр сурәтләнә?

6. Ни өчен гыйлем алу ансат эш түгел? Татарларда бу фикерне раслаучы мәкальне искә төшер.

7. Ничек уйлыйсың, алга таба Әбүгалисина һәм Әбелхарис белән нинди хәлләр булыр икән. Фаразлап кара.

Малай, үзен кызыклы уеннан бүлдергән әнисенә канәгатьсезлек белән карап:

— Суны иртән тору белән алып кайтып куйсаң булмый идемени? — дигән.

— Иртүк алып кайтсам, көне буе җылынып бетәр дигән идем. Син бит кичләрен, уеннан арып кайткач, салкын су эчәргә яратасың, — дигән малайның әнисе.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

— Улым, — дигән әнисе аңарга, — суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

Малай, чиләген күтәреп, урамга чыккан. Кулын кашына куеп, Көймә тавына таба караган. Көймә тавы бик-бик еракта, зәңгәр офыклар артында булып күренгән аңа. Җитмәсә, кояшы өтеп алырдай итеп кыздыра икән.

«Мондый кызуда шул тиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле», — дип уйлаган малай һәм, чиләген бер читкә куеп, өр-яңадан уйнарга тотынган. Үзенең бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән.

- Мәкаль белән бәхәскә кереп булмый *(азәрбайҗан мәкале)*.
- Яңгыр туктый — кунак китә *(бурят мәкале)*.
- Зур корабка тирән су кирәк *(инглиз мәкале)*.
- Сүз кыска булганда яхшы *(казакъ мәкале)*.
- Корыган агачның җимеше дә булмый *(төрек мәкале)*.
- Яхшы атны тайдан, яхшы кешене баласыннан белеп була *(дагстан мәкале)*.
- Эшләгәндә, кояшны үзең уят *(удмурт мәкале)*.

Татар халкының мәкаль һәм әйтемнәрен, фразеологик әйтелмәләрен туплау һәм өйрәнүгә галимнәребез Нәкый Исәнбәт, Хуҗиәхмәт Мәхмүтовлар зур өлеш кертә.

Татар халкының күренекле шәхесләре

Хуҗиәхмәт Мәхмүтов *— галим, әдәбиятчы, фольклорчы, Халыкара төрки академия академигы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Фәнни эшчәнлеге Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйле. Галим татар халык авыз иҗатының афористик жанрларын тирәнтен өйрәнә. Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр, мәзәкләрне туплау, бастырып чыгаруга зур өлеш кертә. Бу өлкәгә караган утызлап хезмәте бар. «Кечкенә дә төш кенә», «Ел тәүлеге — 12 ай», «Канатлы сүз — хикмәтле сүз» китаплары фәнни һәм мавыктыргыч телдә язылган.*

МӘКАЛЬЛӘР

- Вакыт акчадан кадерлерәк.
- Акчаңны югалтсаң да, акылыңны югалтма.
- Алмагачны ашласаң, тәмле алма ашарсың.
- Талчыбыкны яшьтән бөгү җайлы.
- Белеме ничек — сүзе шундый.
- Анасына өргән эт бүре авызына төшәр.
- Туган телең — иркә гөлең, кадерләмәсәң сулар.
- Илен белмәгәннән игелек көтмә.
- Битеңне бизәмә — акылыңны бизә.
- Кәкре үсеп картайган агачны төз итеп булмый.
- Йөзек кашы зур булмый.
- Алтыда белгән алтмышта онытылмас.
- Милләт телен белгән милекле булыр, халкына игелекле булыр.
- Киемне зиннәтләүгә караганда акылны зиннәтләү файдалы.
- Иленнән аерылганның канаты каерылган.
- Илдә яшисең икән — илеңә хезмәт ит.
- Акылсызның малы — иләктәге су.
- Туган илең — туган анаң, чит ил — үги анаң.
- Аталы-аналы — алтын канатлы.
- Белгән телең ун булсын, туган телең бер булсын.

ӘЙТЕМНӘР

- Эзгә төшү
- Сыймаганга чөй кагу (урынсыз җирдә катнашу)
- Бер балык башын чәйнәү
- Суган сату

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ
РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Риваять гарәп телендә «хәбәр, хикәят» дигәнне аңлата
ләр — үткәндәге вакыйгаларны, ыру-кабилә, халык тарихын, җи
фик атамаларның килеп чыгышын, тарихи шәхесләр тормышы б
хәлләрне сөйләүче халык авыз иҗаты әсәрләре.

Риваятьләр халыкның хәтерен саклый, аны алдагы буыннарга
Легендалар һәм мифлар белән чагыштырганда, алар дөреслек
була. Риваятьләрне тематик яктан *тарихи*, *топонимик*, *көнкүре*
аералар.

Тарихи риваятьләрдә булган вакыйгалар, аларда катнаш
хи шәхесләр турында бәян ителә. Топонимик риваятьләрдә
понимик атамаларның ничек барлыкка килгәнлеге аңлатыла.
риваятьләре аерым бер гаилә тормышында чагылыш тапка
хәлләр, фаҗигале язмышлар, мәхәббәт тарихлары турында сө

ШӘҺӘР НИ ӨЧЕН КАЗАН ДИП АТАЛГАН?
(*Риваять*)

Казан бәкләреннән берәүнең бер хезмәтчесе булган. Ул бакыр ка
елгага суга килгән. Елганың кырые текә ярлы, су алыр өчен уңайсыз икән. Ул, шундый уңайсыз җирдән су алам дип азапланганда, кулындагы бакыр казанын су төбенә төшереп җибәргән. Менә шуннан соң бу елга Казан дип аталган икән. Казан елгасы буена корылган шәһәр дә шул ук исем белән «Казан» дип аталган.

3. Легендалар һәм риваятьләр

? ● Айга ничек менеп була?

Татар халык авыз иҗатында мифларга якын булган риваять һәм легенда жанрындагы әсәрләр дә бар. Алар тормыштагы төрле вакыйга, хәлләр, күренешләр турында мавыктыргыч итеп сөйләп бирәләр. Аларда халык авыз иҗатына хас булган образлылык, мавыктыргыч итеп хикәяләү, чынбарлык һәм уйдырма кушылып китә. Легенда һәм риваятьләр чәчмә һәм тезмә формада була.

Легенда — нигезендә фантастик образ яки күзаллау яткан халык хикәясе. Латин теленнән алынган бу сүз «укырга тиешле нәрсә» дигәнне аңлата. Легендаларда тормыштагы күренеш-вакыйгалар фантастик күзаллау аша тасвирлана, хыялый образлар тудырыла, уйдырма хәлләр турында сөйләнелә. Гыйбрәтле вакыйгалар аша тәрбия бирү дә күздә тотыла.

Легендалар эчтәлекләре белән төрле темага карыйлар.

Көнкүреш легендаларында уйдырма вакыйгалар яки хәлләр тормыш-көнкүрешкә бәйләп сөйләнелә. Төрле хайван һәм кош-кортларның барлыкка килүен, аларга хас билгеләр турында сөйләгән легендалар – *зоогоник*, географик атамаларның килеп чыгышын уйдырмага нигезләп аңлатканнары — *топонимик*, күк җисемнәре белән бәйле темага караганнары — *космогоник*, тарихи вакыйга һәм шәхесләргә багышланганнары *тарихи легендалар* дип йөртелә.

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Татар халкының күренекле шәхесләре

«Шүрәле» әкият-поэмасын, халык әкиятенә нигезләнеп, татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай язган.

Габдулла Тукай язның иң матур вакытында — 26 апрельдә 1886 елда туган. Туган җире — хәзерге Татарстан республикасы Арча районы Кушлавыч авылы. Әтисе Мөхәммәтгариф шул авылның мулласы була. Булачак шагыйрьгә биш ай чакта аның атасы, дүрт яшендә әнисе үлә. Шулай итеп, ул бик яшьли ятим кала. Шул вакыттан башлап, аңа төрле гаиләләрдә, төрле җирләрдә яшәргә туры килә. Габдулланың исендә ник уелып калган вакыты Кырлай авылында Сәгъди абзый гаиләсендә яшәгән чоры була. Габдулла Кырлайда ике-өч ел чамасы яши. Беренче елны абыстайга, икенче елны мәдрәсәгә йөреп, башлангыч белем ала. Габдулла Тукай үзе дә: «Бу Кырлай авылы — минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным», — дип яза.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Татарстан Республикасы Арча районы Яңа Кырлай авылында 1892 — 1894 елларда Габдулла Тукай яшәгән Сәгъди абзый нигезендә хәзер музей-йорт тора. Анда барлык корылмалар да Габдулла яшәгән еллардагыча итеп урнаштырылган. Йорт эчендәге җиһазлар да XIX гасырдагы гади крестьян тормышын сурәтли.

Соңыннан Габдулланы Җаек (Уральский) шәһәрендә яшәүче, әтисе белән бертуган апасы Газизә үз гаиләсенә алдыра. Бу шәһәрдә ул шагыйрь булып өлгерә.

Кызганычка каршы, Габдулла Тукай бик яшьли, нибары 27 ел гына яшәп вафат була. Кыска гомере эчендә бик күп әсәрләр иҗат итеп калдыра. Балалар өчен язылган әкият, шигырьләре бүген дә иң яратылып, иң күп укыла торган әсәрләрдән санала.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Ямщик — почта яки кешеләр ташый торган атларны йөртүче. Ямщик — төрки сүз. «Ям» сүзе Алтын Урда ханнары ярлыкларында да очрый.

Ямщик, Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан алтмыш кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?!» — дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган. Ул мине асрау бала итеп өенә алып кайткан.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Печән базары — XVIII гасырда Казанның Иске татар бистәсендә урнашкан сәүдә үзәге. Монда арбалардан печән, утын, мунчала сатканнар. Биредә шулай ук башка төрле сәүдә рәтләре һәм каравыл йорты булган.

Базарның үзәгендә Печән базары мәчете урнашкан. Бүген аны Нурулла мәчете дип йөртәләр.

Печән базары Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрендә тәфсилләп тасвирлана.

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам. Мәсәлән, бервакыт, әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта, мине бер

Ара-тирә әни дә: «Юк, бездә кешегә бирә торган бала юк!» — дип куйгалый иде.

Мосафир Бәдретдин абзый: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга, мин хәзер үрәдниккә әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне падсуд җибәрермен», — дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара әти-әни йомшардылар.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Урядник — патша армиясенең казак гаскәрләрендә хезмәт итүче офицер, өяз полициясе хезмәткәре.

Бераздан минем әнием: «Я, атасы, бирик инде; ахры, кеше баласы безгә булмас, Аллаһы сакласын, әллә ниләр күрербез», — дип, үкереп елап та җибәрде.

Озакламый, җил басылганнан соң да бераз дулкынланып торган диңгез кебек, актык һәм йомшак тартышу белән генә тартышкач, әти дә разый булды.

Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарымны кидереп, күп тә үтми мине арбага чыгарып утырттылар.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Киез ката — ирләр һәм хатыннар кышын киеп йөргән аяк кием е. Ул итек кебек озын балтырлы яки кунычсыз, кәвеш формасында итеп йоннан басылган була. Аларны өйдә кию өчен дә басканнар. Бүген дә безнең тормышта сакланып килә.

Әти-әни, бичаралар, һәр икесе елаган хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар.

Ахырда әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве булырсың», — дип, ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек. Минем китү мәсьәләм бөтенләе ярты сәгать диярлек аз вакытта хәл ителгәнгә, авылдагы иптәшләр һәм танышлар белән күрешә алмадым. Алар безми калдылар.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Тамбур белән чигү. Татар кул эше осталары тамбур белән яратып чиккәннәр. Тамбур белән чигү кулланылганда бизәк атлам-чылбырлар ярдәмендә ясала. Тамбур белән чигү өчен махсус энә кулланыла (күз урынына ыргакчыгы була). Тамбур белән чигү французча tambour (барабан) дигән сүздән алынган, чөнки тукыма тарттырылган түгәрәк киерге барабанны хәтерләткән. Бу төр чигү татарларда гына түгел, ә бик күп төрки халыкларда (төрекмән, башкорт, үзбәк, азәрбайҗан, казакъ, кыргыз) киң таралган була. Тамбур белән чигүнең ике төре бар. Күпертүле тамбур йон җепләрдән вак атламнар белән, яссы тамбур нечкә ефәк яки киҗе-мамык җепләр белән чигелә.

Икенче күренеш

Исмәгыйль. Сәрвәр җаным, сиңа — сөенеч, үземә көенеч хәбәр ки-

Сораулар һәм биремнәр

1. «Шәһәр ни өчен Казан дип аталган?» риваяте нәрсә турында?
2. Риваятьтә фантастик вакыйгалар яки фантастик образлар бармы?
3. Анда сөйләнгән вакыйгаларның чын булуы мөмкинме? Ни өчен шулай уйларга була?
4. Риваять легендадан ничек аерыла? «Зөһрә кыз» легендасының һәм «Шәһәр ни өчен Казан дип аталган?» риваятендәге вакыйгаларның чынбарлыкка якынлыгын чагыштырып кара.
5. Риваять нәрсә ул?
6. «Шәһәр ни өчен Казан дип аталган?» риваятен кайсы тематик төргә кертергә мөмкин? Ни өчен?

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Хәзерге вакытта Казан каласының яше мең ел дип исәпләнә. Шәһәрнең меңьеллыгы рәсми рәвештә 2005 елда Бөтенроссия дәрәҗәсендә билгеләп үтелде. Казанның яшен билгеләү эшен татар тарихчысы Альфред Халиков җитәкләп, табылдыкларны өйрәнүгә Россиянең егерме шәһәреннән һәм дөньяның егерме иле ннән белгечләр җәлеп ителгән була. Казан Кремлендә казу эшләре барышында табылган, 929—930 елларда сугылган Чехия тәңкәсе, һөнәр һәм хуҗалык әйберләре, башка артефактлар шәһәрнең 1000 ел элек үк яшәгәнен раслады.

Җиңел, уенчак һәм шат булган, моңландырмаган, сагындырмаган, тынычландырмаган, юаткан.

Тагы бер кат аңар карагыз әле! Аның уртасында, нәкъ уртасында көянтәчиләкләр күтәргән бер кыз басып тора бит. Ул татар кызы — Зөһрә кыз. Аның озын, бик озын кара чәч толымнары очында авыр-авыр чулпылары асылынып торалар. Аның озын керфекләре, оялчан кара күзләре җиргә карап торалар...

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Чулпы — татар хатын-кызларының көндәлек киелә торган бизәнү әйбере. Татар хатын-кызларының икегә аерып үрелгән чәч толымының очларына чулпы тагылган. Аны гомер буена тагып йөргәннәр.

Казан татарларында бик борынгыдан ук көянтәле чулпы кулланылган. Мондый чулпыларның күптөрле үрнәкләре Казандагы тарих музеенда саклана. Чулпыларның тәңкә һәм асылмалары төрледән-төрле асылташлар, төсле пыялалар белән дә бизәлгән. Чулпыны бизәүдә кызыл сердолик исемле ташны бик яратып кулланганнар.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Калфак — татар хатын-кызларында киң таралган баш киеме. Ул чигүләр, төрле ташлар белән бизәлә, шулай ук алтын һәм көмеш җепләр белән тегелә. Калфакның төрле формалары була. Яшь кызлар, олы ханымнар калфагы да, көндәлек һәм бәйрәмнәрдә кия торган калфаклар да формасы, бизәлеше белән аерыла.

— Ачылып җиткән бу чәчәкнең янына ачылып килә торган бер чәчәк тә ясап бирсәм ничек булыр? — дидем мин Мәрфуга апага.

— Алай ясап буламы соң? Аны ясап булса, бигрәк тә матур, бигрәк тә тулы булыр иде, — диде ул.

Мин яфраклар арасына телкәйләрен яңа ачып җибәрә торган бер кечкенә чәчәк тә ясап куйдым. Болай иткәч, рәсем, чынлап та, тулырак булып китте, тагы да матур иде.

— Кечкенә гөнә куллары белән нинди матур чәчәкләрне нинди оста итеп ясый белә бит! — дип, Мәрфуга апа, елмаеп, иркәләү карашы белән минем күзләремә туп-туры карады.

Көннәрдән бер көнне без абый белән уйнарга тотындык: иске тарантасыбыз пролётка урынында, аның югары күтәреп бәйләнгән тәртәләре ат урынында, абый — бай, мин кучер булдык. Абый: «Киттек!» — дип кычкыргач, мин, тарантасның кучер аягы басар өчен куелган тактасына аякларым белән тибеп, ат барган кебек тавыш чыгарырга тотындым. Ат кузгалды, без киттек, имеш!

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Тарантас – утырып йөрү өчен көйләнгән дүрт көпчәкле озын артлы җиңел арба. Аның тарантас арба дигән төре дә бар. Ул — өс-тенә чыбыктан үрелгән җайланма беркетелгән арба.

Берничә минутлар шулай баргач, абый миңа:

— Атны чаптыра төш! — диде.

Мин дә аякларымны бөтен көчләре белән тыпырчындырырга башладым. Очабыз гына, имеш!

Бу арада апа, тәрәзәне ачып:

— Гомәр, кер әле монда. Безгә курай уйнарсың! — дип кычкырды.

Милли-мәдәни һәм тарихи мирасыбыздан

Курай — татар һәм башкорт халыкларының милли тынлы музыка коралы. Татарларда курай элек-электән үк киң таралган. Исеме чатыр чәчәкле үсемлекләрнең куыш сабагы «кура көпшә»дән барлыкка килгән. Курайлар күптөрле була (агач курай, камыл курай, җиз курай, бакыр курай). Гадәттә, курайларның озынлыгын тотам (кул киңлеге) белән үлчиләр. Шуннан чыгып, курайлар җиде, сигез, тугыз, яисә ун тотамлы озынлыкта булалар. Курайның тавышы материалына, озынлыгына, юанлыгына да бәйле.

2

Ул көн кич йокларга яткач, мин үземнең шул дулавым хакында бик озак уйландым. Бер караганда, апа, Мәрфуга апа, әни, абый, хәтта теге кунак кызлары да мине җәбер иткәннәр шикелле тоелалар, икенче караганда, мин үзем болай сугыша башлап начар эшләгәнмен шикелле тоела. Башкалары тагын бер хәл иде, Мәрфуга апа алдында мин үземне оятлы итеп сизәм.

Ул мине акылсыз малай икән бу дип уйлагандыр инде... Абыйны алар һөнәре өчен чакырып алалар икән, Мәрфуга апа мине бигрәк һөнәрсез малай бит бу дип уйлый торгандыр...

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

ларга күчерде. Лотфулла абзый итне чапкалап бизмәнгә салып үлчәп бетергәнче, Габдулла тагын бераз укып өлгерде. Итнең кәгазьгә төрелеп өстәлгә шап итеп куелуы гына аңа укуын бүләргә кирәклекне искәртте. Ул, акчаны түләп, итне кәрзингә салды. Шулай да аучы әкиятен укып бетерми торып китәсе килмәде:

— Лотфулла абзый, менә моны гына укып бетеримче? — дип сорады.

— Укы, укы! — диде кибетче. — Теләсәң менә тагын! — дип, ул икенче җирдән бер өем кәгазьне өстәлгә, әлеге кәгазьләр өстенә китереп салды: йомышка йөрүче малайларны үз кибетенә ияләштерер өчен алар белән мөмкин хәтле ягымлы һәм сүзчән булырга тырыша иде ул. Габдулла рәхәтләнде генә! Хуҗаның рөхсәте дә булгач, ул бер уч кәгазьне үзенең алдына алып, кибет янындагы зур ташка утырды һәм сурәтләрне карарга, аларның астына язылган сүзләрне укырга тотынды. Ул шулкадәр мавыгып китте, ит кибете янында иснәнеп йөрүче зур кара маэмайның кәрзин янына килеп җитүен сизми дә калды. Кинәт кәрзин авып китте, Габдулла сикереп торды һәм, куркып, бөтен көче белән:

ФИРЯ
ФЕДЕРАЛЬНЫЙ ИНСТИТУТ РОДНЫХ ЯЗЫКОВ НАРОДОВ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Благодарим за внимание!